## Курчак театры, Tiki-Viki һәм башкалар

**/Безнең сәяхәтләр/**




Мәктәп лагерына йөргән көннәрдән минем өчен иң кызыклысы Казанга барган көн булды. Бер матур көнне без иртән үк мәктәп автобусына утырышып Казанга да юл тоттык. Казанга килеп җиткәч иң беренче итеп без “Әкият” театры каршындагы чәчәкләрдән ясалган фигураларны карап күңелебезне “матурладык”. Аннан соң курчак театрына кереп “Кәҗә белән Сарык” әкиятен карадык. Әкият бик кызыклы һәм заманча итеп күрсәтелде.

Курчак театрын карап чыккач апалар безне кафега алып кереп ашаттылар. Аннан соң “Tiki-Viki” дигән уен залына барып, төрле аттракционнарда уйнадык. Без анда уйнап кына калмадык, төрле җирләрдән килгән яшьтәшләребез белән дуслашырга да өлгердек. Безнең малайлар бигрәк тә шәһәр кызлары белән күп аралашты. Уйнап арыгач, әлбәттә, ашыйсы килде. Без уйнаган вакытта ук апалар тәмле ризыклар алып килеп куйганнар иде.

Казанга барган көнебез шулай матур үтте. Авылга кайтканда, аруларыбызны онытып, күңелле җырлар җырлап кайттык. Безне Казанга алып барган апаларга һәм автобус йөртүчесе Рифкать абыйга бик зур рәхмәт!

*Кәүсәр Насыйрова, IV сыйныф укучысы*

---

## Хуҗалар тавында булдык



Мин бу җәйне дә үзебезнең мәктәп лагеренда ял иттем. Лагерь ябылу көнен истәлекле итеп үткәрү өчен апалар безне Хуҗалар тавына алып бардылар.

Хуҗалар тавына барып җиткәч, без матур җиргә урнаштык та, Биләрдәге тәвә кошлары фермасына киттек. Монда кечкенә генә бер зоопарк икән! Миңа иң ошаган хайван дөя булды. Ә кошлар арасында иң матуры – тәвә кошы. Бу фермада куян, кәҗә кебек безнең як хайваннары һәм балыклар да яши. Аларның һәрберсенең холкы үзенчә, һәркайсы үзенчә матур.

Ферманы карап чыкканнан соң, тагын Хуҗалар тавына килдек. Пешекче апалар безне тәмле ризык әзерләп, көтеп тора иделәр. Безнең бабай учакта купаты кыздырып бирде. Туңдырмалар белән дә сыйлангач, чишмәгә барып су эчтек. Кибеткә кереп уенчыклар алдык. Көнебез кызыклы узганлыктан, кайтыр вакыт җиткәнен сизмичә дә калдык. Күңелем белән бу көннең тагын кабатлануын теләп кайттым. Апаларыбызга рәхмәт әйтеп калам иптәшләрем исеменнән дә.

*Ләйсән Закирова, IV сыйныф укучысы*

## Сабан Туйларыннан җыелган уңыш

**/Безнең спорт/**



Җәйге спорт төрләре, беренче чиратта, милли бәйрәмебез – Сабан Туйлары белән бәйле. Алдагы еллардагы кебек үк, быелгы җәй дә безнең көрәшчеләр өчен уңышлы булды.

Узган бәйгеләр аеруча X сыйныф укучысы **Илдус Камаловка** зур җиңүләр китерде. Авыл Сабан Туеның батыры булганнан соң Илдус **Аксубай, Норлат, Чистай районнары** Сабан Туйларында, һәм Әлки районының Хузангай авылында үткән чуаш халкының **Бөтенроссия Уяв бәйрәмендә** беренче урыннарны алуга ирешә.

Авыл Сабан Туенда үз авырлыкларында **Галимов Рияз – I, Хәбибрахманов Әхмәт – II, Сидоров Рома – III** урыннарны алдылар. **Аксубай районы** Сабан Туенда 55 кг авырлыктагылар арасында **Хәбибрахманов Әхмәт – I, Галимов Рияз – II** урыннарны яуладылар. **Чистай шәһәре** Сабан Туенда яшь көрәшчебез **Җамалетдинов Зөлфәт – II,** мәктәпне тәмамлап китүче укучыбыз Нурматов Халид – III урыннарны алдылар.

Узган ел мәктәпне тәмамлаган укучыларыбыздан **Хәбибрахманов Ильяс Түбән Кама шәһәре** Сабан Туенда яшь көрәшчеләр арасында **I** урынны яулады.

## Җәйге шахмат бәйгеләре

Мәктәбебезнең шахматчысы **Гафиятуллин Фаилнең** җәйге яллары беренче көннән үк турнирлар белән башланып китте. Фаилнең җәйге уңышлары түбәндәгеләр: Чистай шәһәрендә узган Бөек Ватан сугышында җиңүнең 77 еллыгына багышланган блиц-турнирда – I, Бөтендөнья физкультура көненә багышланган ярышта – II урыннар; Сабан Туе бәйрәменә багышланган район турнирында – I урын; Бөгелмә шәһәрендә узган Кама аръягы Гран-приенең 3 нче этабында – III урын. Афәрин Фаил, һәрвакыттагыча булдырасың!


**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**
**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**
**<u>Редколлегия әгъзалары:</u> Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина**



# Мәктәп хәбәрчесе

**№6** (№37) июнь-август 2022 ел

**Түбән Майна урта мәктәбе газите**



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


**/Мәктәп тормышы/**

## Зур тормышка – Шәһри Болгардан



Әле кайчан гына чыгарылыш сыйныф укучыларын туган мәктәпләреннән озатып Соңгы кыңгырау яңгыраган иде. Инде менә дәүләт имтиханнарын тапшырганнан соң аттестат алу вакыты да килеп җитте. Өлгергәнлек аттестатын алу – кеше гомерендәге иң дулкынландыргыч һәм шатлыклы вакыйгадыр ул. Шушы мизгелдән бала зур тормышка юл ала! Мәктәп белән хушлашуның чыгарылыш сыйныф укучылары һәм аларның әти-әниләре өчен күңелләргә уелып, хатирәле һәм тирән мәгънәле булып калуы мөһим. Шуның өчен, узган елдан алып, безнең мәктәптә аттестат тапшыру тантанасын Ватаныбызның истәлекле урыннарында уздыру тәртибе кертелде. Үткән елгы чыгарылыш сыйныфлар аттестатларын Тукайның туган ягы булган Кырлайда алсалар, быелгы тантана, Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы хөрмәтенә, Шәһри Болгарда уздырылды.

Шәһри Болгарга сәфәребезне мәктәп директоры Рафик абый юл буендагы барча истәлекле урыннар белән таныштырырлык итеп оештырган. Иң беренче тукталышыбыз үзебезнең күршедәге **Биләр шәһәрлегендә** булды. Башта борынгы башкалабызның үзәк өлешенә кереп биредәге җәмигъ мәчет һәм төрле бина нигезләрен күреп чыктык. Без килгән вакытта археологлар да эшләрен башлап җибәргән иде. Аларның җитәкчесе Альберт абый Нигамаев үзләренең эшчәнлеге турында сөйләп үтте. Биләр истәлекләре белән танышу **“Хуҗалар тавы”** комплексында дәвам итте. Биредәге музей күргәзмәләре белән Рафик абый үзе таныштырды.

Юлыбызны дәвам итеп **Колбай Мораса** авылы музеена туктадык. Биредә татар милли театр сәнгатенә нигез салучы Габдулла Кариевның тормышы һәм иҗаты белән таныштык. Колбай Морасадан Әлки районы үзәге булган **Базарлы Матакка** юл алдык. Биредә урнашкан туган якны өйрәнү музеенда кайберләребезнең элек тә булганы бар иде. Әлеге музей аның төп бинасының элеккеге хуҗасы булган сәүдәгәр С.М.Лисенков исемен йөртә. Аны оештырып җибәрүдә хәзерге вакытта АКШтагы НАСА космик тикшеренүләр үзәгендә эшләүче онының ярдәме зур булган. Шуңа күрә Әлки музеенда туган як тарихына багышланган гадәти экспозицияләрдән тыш космонавтика буенча аерым зур бүлек бар.

**Шәһри Болгарга** барып җитүне төш вакытына планлаштырган идек, шулай булды да. Ак мәчет комплексын, Икмәк музейларын карап, төшке ашны ашаганнан соң, Болгарның тарихи үзәгенә киттек. Безне тыюлыкка кергәндә күптәнге танышыбыз, Болгар музееның өлкән фәнни хезмәткәре Җәмил абый Мөхәммәтшин каршы алды. Болгарга элеккеге сәфәрләребез вакытында да ул безгә бай эчтәлекле сәяхәтләр оештырып килде. Быелгысы өчен аеруча рәхмәтле булып калачакбыз. Чөнки Җәмил абый безнең укучыларга аттестат алу тантанасын Коръән музеенда уздыру мөмкинлеген кайгырткан. Аның әйтүе буенча, Изге китап сакланган урында төрле хөрмәтле кунаклар катнашында бик күп мәртәбәле җыеннар уздырылса да, чыгарылыш кичәсен безгә кадәр әле уздыручы булмаган. Өлгергәнлек аттестатын алган һәр укучыга истәлек итеп, ханбикә булып киенгән музей хезмәткәре Люция ханым Болгар тарихы турындагы бик матур китаплар өләште. Тантаналы чарадан соң Болгарның зур музее һәм тарихи биналары белән танышып чыктык. Сәфәребез Кече манара янында күмәкләшеп **“Туган тел”** җырын башкару белән тәгәлләнде.

Мәктәбебез укучыларына һәм укытучыларга шундый истәлекле чара үткәргәннәре өчен Рафик һәм Җәмил абыйларга олы рәхмәтләребезне җиткерәбез. Укучыларым олы тормышка таба тәүге адымнарын мөбарәк Болгар җиреннән атладылар. Шуңа күрә дә алдагы гомерләренең хәерле булачагына ышанычым зур. Алла бирсә, һичшиксез шулай булыр: тормыш сынауларын уңышлы үтәргә тырышлыклары, сабырлыклары, ихтыяр көчләре җитәрлек бит аларда.

*Фәнүзә Гафиятуллина, XI сыйныф җитәкчесе*

/Рәсми хәбәрләр/

## Чыгарылыш имтиханнары нәтиҗәләре

2021-2022 нче уку елын XI сыйныфтан 4, IX сыйныфтан 7 укучы тәгәлләде. XI сыйныфлар бердәм дәүләт имтиханының сайланма төрләреннән җәмгыять белеме, рус әдәбияты, биология фәннәрен тапшырдылар. IX сыйныф укучылары мәҗбүри математика һәм рус теленнән тыш информатика һәм география фәннәрен сайладылар. Имтихан нәтиҗәләре белән түбәндәге таблицадан танышырга мөмкин:

| Предмет | Укучылар | Укытучылар | Билге | Баллар | Район буенча уртача балл |
|---|---|---|---|---|---|
| Математика (профиль) | Мөхәммәтова Рузилә | Хәсәнова Р.Х. | | 40 | 64,15 |
| | Нурматов Халит | | | 78 | |
| | Сафиуллин Фазыл | | | 68 | |
| | Уртача | | | 62 | |
| Математика (база) | Насыйрова Сара | | 5 | - | |
| Рус теле | Мөхәммәтова Рузилә | Нәҗметдинова Р.Р. | | 67 | 70,51 |
| | Нурматов Халит | | | 72 | |
| | Сафиуллин Фазыл | | | 76 | |
| | Насыйрова Сара | | | 72 | |
| | Уртача | | | 71,75 | |
| Рус әдәбияты | Насыйрова Сара | Нәҗметдинова Р.Р. | | 77 | 72,33 |
| Биология | Мөхәммәтова Рузилә | Туктамышев Р.Т | | 48 | 54,65 |
| Җәмгыять белеме | Мөхәммәтова Рузилә | Насыров Р.Г. | | 61 | 72,27 |
| | Насыйрова Сара | | | 65 | |
| | Нурматов Халит | | | 76 | |
| | Сафиуллин Фазыл | | | 56 | |
| | Уртача | | | 64 | |

Укучыларыбыз сайлаган уку йортларына югарыда китерелгән баллары белән уздылар. Мөхәммәтова Рузилә Казан инновацион институтының экономика, Насыйрова Сара КФУның сәнгать һәм инглиз теле белгечлеге буенча белем алачаклар. Нурматов Халит Чаллы дәүләт педагогия университетының математика-информатика бүлегендә укуын дәвам итә. Сафиуллин Фазыл КНИТУ ның техник көллиятендә бухгалтер белгечлеген үзләштерәчәк.

IX сыйныфтан Ахсанов Халит Әлмәт шәһәрендә нефть техникумында, Хөснуллин Марат белән Сидоров Роман Аксубай техникумында укуларын дәвам итәчәкләр. Төп мәктәп курсын тәмамлаган укучыларның өчесе урта белем алу өчен мәктәптә калдылар.

*Илдар Сафиуллин, уку-укыту буенча директор урынбасары*

/Безнең бәйрәмнәр/



## Корбан бәйрәме

Безнең мәктәптә тәрбия чаралары даими рәвештә уздырылып килә. Шулар арасында Рамазан гаете белән Корбан гаете аерым игътибарга лаек. Быелгысы елда Корбан гаете мәктәп, мәдәният йорты хезмәткәрләре белән берлектә табигатьтә төрле уеннар, ярышлар үткәрү белән уздырды. Авыл халкы шашлык пешерү өчен корбан итеннән өлеш чыгарды. Мәчет тәмле сыйлар алып бирде. 10 нчы июль көнне төштән соң авыл балалары һәм кунакка кайтучылар мәдәният йорты артындагы яшел болынга җыелдылар. Балалар ямьле табигать кочагында рәхәтләнеп күңел ачты. Аеруча ошаганы ярыш рәвешендә оештырылган кумәк уеннар булды. Ярышларны укытучы апалар, мәдәният йорты җитәкчесе Гүзәлия апа оештырды. Уеннардан соң балалар яшел чирәмгә җәелгән бәйрәм табыннары артына җыелышып тәм-томнар һәм шашлык белән сыйланды.

Шулай итеп, Корбан гаетендә без чын күңелдән ял иттек. Авыл халкына, мәчет әһелләренә, оештыручы апа-абыйларга рәхмәтебезне җиткереп калабыз.

*Виктория Нукина, X сыйныф укучысы*

/Мәктәп тормышы/

## “Дуслык” лагерында ял иттек



Мәктәптә җәйге чор – тәмамланган уку елы белән киләсе уку елы арасында үзенә күрә бер күпер ул. Тикмәгә генә җәй айларын уку елының бишенче чиреге дип атамыйбыз. Каникуллар балаларның иҗади активлыгын үстерү, тәрбияләү һәм сәламәтләндерү өчен мөһим роль уйныйлар. Менә шуларны истә тотып мәктәбебездә ел саен укучылар өчен җәйге лагерь оештырыла.

Лагерь ачылыр алдыннан бик мәшәкатьле әзерлек эшләре алып барыла. Мәктәп хезмәткәрләре арасыннан кадрлар туплана, күпсанлы документлар Роспотребнадзор органнары белән килештерелә. Тәрбияләнүчеләрнең мәнфәгатьләрен истә тотып эш планы төзелә. Балаларга көн саен ял итү өчен барлык шартлар тудырыла: уку кабинетларында уен һәм ял итү бүлмәләре булдырыла. Ашханә, спортзал һәм урамдагы спорт мәйданчыгы лагерьга тапшырыла.

Лагерьга килгән балалар ике төркемгә бүленеп, һәрберсенә аерым тәрбияче билгеләнә. Төркемнәрдәге көнлек программа укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап оештырыла. Тәрбиячеләр һәр көнне физкультминуткалар уздыра, кабинетларда рәсем конкурслары һәм башка чаралар үткәрелә. Лагерь барышында шулай укучылар арасында шахмат-шашка турнирлары, төрле тематик квестлар уздырылды. Егет-кызларыбыз үзләрен пешекче ролендә да сынап карадылар. Берничә тапкыр үзләре яраткан гамбургерны ясадылар. Укучылар үзләрен сәхнә әһелләре буларак та сынап карадылар. Ике төркем дә яраткан әкиятләрен өйрәнеп, мәдәният йортында сәхнәдә бәләкәй тамашачылар алдында чыгыш ясады. Сәнгать, рәсем белән генә канәгатьләнмичә, тормышта кирәкле нәрсәләрне дә өйрәндек. Шулай беркөнне “Яшел аптека” дигән экскурсиягә чыктык. Укучылар белән авылыбызда үскән файдалы үләннәр белән танышып кайттык.

Һәркөн бертөрле генә узмасын өчен “Дуслык” лагеры тәрбиячеләре укучыларны төрле экскурсияләргә йөртте. Беренче экскурсиябезне без мәчеттән башлап җибәрдек. Мәчеттә балаларны көтеп алган Гөлүсә апалары үзебезнең дини йолаларыбыз турында сөйләде. Укучылар исә, бер-берсенә белгән догаларын укып күрсәттеләр. Икенче экскурсиябез безнең китапханә булды. Авылыбызның китапханәчесе Рузилә апалары балаларны яңа китаплар белән таныштырды һәм китапханәгә ешрак йөрергә өндәде. Экскурсияләребезне дәвам итеп мәдәният йортына да юл тоттык. Безне Гүзәлия апа киң күңел белән каршы алды. Балалар апалары белән берлектә үзебезнең татар халык уеннарын уйнадылар, белгән шигырьләрен сөйләделәр, җырлар җырладылар. Соңыннан заманча дискотека да булды. Экскурсияләр авыл белән генә чикләнеп калмады. “Дуслык” лагеры балаларны район үзәгендәге бассейн белән спорткомплекска, тарихи Биләргә һәм башкалабыз Казанга да алып барды.

Лагерьда үткән һәр көн алдагысына охшамаган һәм яңа тәэсирләр белән тулган иде. Һәр бала өчен лагерь яңа яктан ачылды: берәүләр моның кызык икәнен белде, кемдер үзендә яңа иҗади сәләтләр ачты, ә кемдер җиңелә белергә өйрәнде. “Дуслык” лагерында узган көннәр балаларда онытылмаслык тәэсирләр, файдалы күнекмәләр һәм күңелле истәлекләр калдыргандыр дип өметләнәбез.

*Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы*

## Рәхмәт сүзе

Балаларыбыз мәктәпкә уку дәверендә дә теләп, яратып йөри. Җәйге каникул көннәрендә дә укучыларга вакытларын файдалы һәм күңелле итеп уздыру мөмкинлеге бирелә. Шундый күңелле лагерь оештырган өчен мәктәп директорына, балалар берләштереп йөргән укытучы Фәнил абыйларына, һәр көн кызыклы үтсен дип эшләгән тәрбияче Рузилә, Гөлшат һәм Сирин апаларына, тәмле ризыклар белән сыйлаучы пешекче Илсөяр апаларына, яңгырлы булуга карамастан һәр көнне үз вакытында килеп алган, китереп куйган автобус йөртүчесе Рифкать абыйларына, озата баручы Рузилә апаларына бик зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Киләчәктә дә Раббыбыз сезгә исән-имин эшләргә насыйп итсен!



*Ландыш Галиуллина, Такталы авылыннан*

---

/Котлыйбыз!/

Ямьле җәй айларында дөньяга килгән балалардан бакча төркеменнән **Җамалетдинов Фирдүс** белән **Сафиуллин Исламны,** укучылардан **Сафиуллина Гөлсем**, **Нургатин Фаил**, **Җамалетдинов Зөлфәт, Сәгъдиев Рәмзис**, **Насыйрова Кәүсәр, Сафеева Настя, Галиуллин Әхмәт**, **Нурматова Зәйнәп**, **Залиев Салават**, **Нурматов Мусаны** туган көннәре белән чын күңелдән котлыйбыз. Аларга саулык-сәламәтлек, тырышлык, укуларында уңышлар телибез.

Хезмәткәрләрдән тәрбияче **Насыйрова Гөлүсә апаны,** укытучы **Сафиуллина Алсу апаны**, завхоз **Шакиров Азат абыйны** гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Пешекче **Сабитова Илсөяр апа** белән техничка **Сәгъдиева Галия апаларны** юбилейлары белән котлап сәламәтлек, озын гомер, гаилә иминлеге теләп калабыз.